КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 гыйнвар г.Казань № 69

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 сентябрь, 875 нче; 2019 ел, 15 май, 397 нче; 2021 ел, 19 апрель, 256 нчы; 2021 ел, 5 июль, 544 нче; 2022 ел, 1 март, 187 нче; 2022 ел, 22 июль, 712 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының (алга таба – дәүләт программасы) «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – ярдәмче программа) каралган түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру максатларында тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет акчасын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә:»;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

$11^1$ пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

$11^3$ пунктның өченче абзацында татар текстында «– 14 берәмлек» сүзләрен төшереп калдырырга, «үткәрелгән чаралар саны» сүзләре алдына «килешүдә билгеләнеп» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин